**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Әтнә муниципаль районы**
**Күәм авыл җирлеге**

422740, Әтнә муниципаль районы
Күәм авылы, Х.Такташ урамы, 1 йорт 1003 б
тел. 3-63-39, факс 3-63-39

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Атнинский муниципальный район**
**Кубянское сельское поселение**

422740, Атнинский муниципальный район
с.Кубян, ул. Х.Такташа, 1, пом.1003
тел. 3-63-39, факс 3-63-39

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

27 октябрь 2025 ел. № 3

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы
Күәм авыл җирлеге Каенсар торак пунктында гражданнарның
үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану
мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ номерлы Федераль законының 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы , Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлеге Уставы нигезендә, карар бирәм:

1. 2025 елнын 7 ноябрендә Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлегенә керүче Каенсар торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

1.1.Билгеләргә:

-Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлеге Каенсар торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы- Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлеге Башкарма комитеты;

-гражданнар җыенын үткәрү вакыты – 2025 елның 7 ноябре 11.00 сәгатькә;

-үткәрү урыны – Каенсар авылы, Мир ур., 35 номерлы йорт яны;

1.2. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлеге Башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2025 елның 30 октябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлеге Башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын гражданнарга түбәндәге адрес буенча бирергә: Күәм авылы, Х.Такташ урамы, 1 йорт, 1003 б;

- сайлау хокукына ия булган Җилгелде торак пунктында яшәүчеләр исемлеген төзергә;

- гражданнар җыенына мәгълүмәти материаллар әзерләргә;

- гражданнар җыены турында Каенсар торак пункты халкына мәгълүмат стендлары аша һәм башка ысуллар белән хәбәр итәргә;

1.3. Халык җыенына чыгарылучы түбәндәге мәсьәләне расларга:

"Сез 2026 елда Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлеге Каенсар торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, 1 нче төркем инвалидлардан, махсус хәрби операциядә катнашучы (катнашкан) затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, махсус хәрби операциядә һәлак булган (вафат булган) затларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- Янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгын сүндерү сулыгын урнаштыру, эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

- Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Урамнарны кардан чистарту, эш һәм хезмәтләр өчен түләү).

“РИЗА” “КАРШЫ”

2. Әлеге карарны Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында интернет челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб–адресы буенча, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: pravo.tatarstan.ru веб–адресы һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы, Каенсар авылы Мир урамы 37 нче йорт адресы буенча урнашкан стендка урнаштырырга.

3. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Күәм авыл җирлеге башлыгы: Сәмигуллин Л.Ә.